КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 апрель г.Казань № 210

Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында

Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган һәм (яки) аларга карата махсус хокук (“алтын акция”) гамәлдә булган акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү максатларында, шулай ук “Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында” 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының “Акцияләре Татарстан Республикасы икътисады өчен аеруча мөһим әһәмияткә ия Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре, акционер җәмгыятьләр исемлеген раслау турында” 2004 ел, 8 октябрь, ПУ-614 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәге теркәлгән исемлекләрне расларга:

директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә билгеләнә һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре;

директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре;

директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре;

акцияләренең дәүләт пакетлары “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү

советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре;

акцияләренең дәүләт пакетлары “Ак Барс” холдинг компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте” устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Ак Барс” холдинг компаниясе” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 13 апрель, 257 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 21 декабрь, 1051 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карары белән расланган Акцияләренең дәүләт пакетлары “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 9 февраль, 95 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 05 апрель, 237 нче карары белән расланган Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 29 май, 436 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карары белән расланган Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә билгеләнә һәм (яки) Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 8 сентябрь, 758 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 ел, 3 ноябрь, 940 нчы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 16 октябрь, 763 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карары белән расланган акцияләренең дәүләт пакетлары “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 ел, 7 март, 145 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 1 апрель, 201 нче;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Акционерлык җәмгыятьләренең идарә һәм тикшерү органнарында дәүләт мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү турында» 2010 ел, 5 апрель, 237 нче карары белән расланган акцияләренең дәүләт пакетлары “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 19 сентябрь, 692 нче;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 апрель, 210 нчы
карары белән расланды

Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә билгеләнә һәм (яки) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

1. «Казан оптика-механика заводы» акционерлык җәмгыяте.
2. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлык җәмгыяте.
3. «Радиоприбор» акционерлык җәмгыяте.
4. «Казан вертолет заводы» акционерлык җәмгыяте.

_________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 апрель, 210 нчы
карары белән расланды

Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

1. «Содружество» акционерлык җәмгыяте.
2. «Инновацион индустриаль парк - «Химград» Технополисы» югары технологияләр өлкәсендә техно-парк» акционерлык җәмгыяте.

________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 апрель, 210 нчы
карары белән расланды

Директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләт вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң махсус хокук (“алтын акция”) нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

1. «Казан моторлар төзү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте.
2. «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте.
3. «Камгэсэнергострой» акционерлык җәмгыяте.
4. «Түбән Кама Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте.
5. В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте.
6. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте.

___________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 апрель, 210 нчы
карары белән расланды

Акцияләренең дәүләт пакетлары “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыяте устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Связьинвестнефтехим” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

1. «Ак Барс» акционерлык коммерция банкы (гавами акционерлык җәмгыяте).
2. «Казан моторлар төзү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте.
3. «Казаноргсинтез» гавами акционерлык җәмгыяте.
4. «Казан» халыкара аэропорты» акционерлык җәмгыяте.
5. «Нефтеконсорциум» ябык акционерлык җәмгыяте.
6. В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте.
7. «Татспиртпром» акционерлык җәмгыяте.
8. «Татнефтехиминвест-холдинг» ачык акционерлык җәмгыяте.
9. «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыяте.
10. «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте.
11. «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 2 апрель, 210 нчы
карары белән расланды

Акцияләренең дәүләт пакетлары “Ак Барс” холдинг компаниясе” ачык акционерлык җәмгыяте” устав капиталына кертелгән, директорлар советларына (күзәтү советларына) һәм ревизия комиссияләренә дәүләттән кандидатуралар Татарстан Республикасы Президенты белән килештергәннән соң “Ак Барс” холдинг компаниясе” ачык акционерлык җәмгыятенең вәкаләтле органнары тарафыннан тәкъдим ителә торган акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

1. «А.М. Горький исемендәге Зеленодольск заводы» акционерлык җәмгыяте.
2. «Камгэснергострой» акционерлык җәмгыяте.
3. «Казан «Электроприбор» заводы» ачык акционерлык җәмгыяте.

___________________________